**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 2 декабрендәге 4963 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 4 октябрендәге 4181 номерлы «“Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарына смотр-конкурс” архитектура проектларының Казан ачык конкурсын уздыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарына смотр-конкурс» архитектура проектларының Казан ачык конкурсын оештыру һәм уздыру процессын яхшырту максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 4 октябрендәге 4181 номерлы «“Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарына смотр-конкурс” архитектура проектларының Казан ачык конкурсын уздыру турында»гы карарының 1 номерлы кушымтасындагы III бүлеккә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2024 елның 5 декабреннән алып 2024 елның 7 декабренә кадәр – смотр-конкурс җиңүчеләрен һәм призерларын игълан итү.».

1.2. җиденче абзацта «2024 елның 2 декабре» сүзләрен «2025 елның 31 гыйнвары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы А.Н.Лобовка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**